МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

04.06.2021 г.Казань № 396

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2021 елның 28 июнендә 7766 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2016 елның 18 февралендәге 78 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы халыкның мәш-гульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга күченүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күченеп урнашуда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга күченүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күченеп урнашуда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 18 февралендәге 78 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 16.10.2018 №950, 07.05.2019 №331, 16.11.2019 №1037, 10.02.2020 №82, 22.06.2020 №449, 02.10.2020

№695 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга күченүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күченеп урнашуда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2021 елның « 04 « июнендәге 396 номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга күченүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күченеп урнашуда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 18 февралендәге 78 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга күченүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күченеп урнашуда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

2 бүлектә:

2.5 пунктта:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Халыкка эшкә урнашуда булышлык күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәте күрсәтү турында 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерыкка 13 нче кушымтага туры китерелгән формалы гариза (алга таба – гариза) яки халыкның мәшгульлек үзәге белгече тарафыннан бирелгән халыкны эшкә урнаштыруда булышлык күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәте күрсәтү турында 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерыкка 14 нче кушымтага туры китерелгән формалы тәкъдим (алга таба – халыкның мәшгульлек үзәге белгече тәкъдиме) һәм дәүләт хезмәте алучының халыкның мәшгульлек үзәге белгече тәкъдименә ризалыгы.

2. Эшсез гражданин мөрәҗәгать иткәндә шәхес таныклаучы документ (Россия Федерациясе гражданины паспортын яки аны алмаштыра торган документны; чит ил гражданинының, гражданлыгы булмаган затның шәхесен таныклаучы документны) күрсәтә.

3. Гаилә әгъзалары булган эшсез гражданин эшкә урнашу өчен башка җирлеккә яңа яшәү урынына күченеп урнашуда ярдәм буенча дәүләт хезмәтен алу өчен өстәмә рәвештә түбәндәгеләрне тапшыра:

үзенең гаилә әгъзаларының шәхесен таныклаучы документларның (чит ил гражданинының шәхесен һәм таныклыгын таныклаучы документлар, – чит ил гражданины булган гаилә әгъзасы өчен, гражданлыгы булмаган затның шәхесен таныклаучы документ, – гражданлыгы булмаган зат булып торучы гаилә әгъзасы өчен) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган күчермәләрен;

эшсез гражданинның гаилә әгъзаларыннан яки аларның законлы вәкилләреннән түбәндәгеләрне раслаучы документ (документлар):

аларның шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалык булуын;

эшсез гражданинның персональ белешмәләрне халыкның мәшгульлек үзәгенә тапшырганда алар исеменнән эш йөртүгә вәкаләтле булуын.

Документларның күчермәләре, әгәр алар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә күрсәтелә һәм халыкның мәшгуль үзәге белгече тарафыннан таныклана.

Эшсез гражданин, шул исәптән түбәндәге документларны да тапшыра:

эшсез гражданинның 14 яшенә җитмәгән гаилә әгъзалары тууын дәүләт теркәвенә алу турында чит ил дәүләтенең компетентлы органнарыннан бирелгән таныклык (алга таба – туу турында таныклык) һәм аның рус теленә нотариаль таныкланган тәрҗемәсе;

өйләнешүне дәүләт теркәвенә алу турында чит ил дәүләтенең компетентлы органнарыннан бирелгән таныклык (алга таба – өйләнешү турында таныклык) һәм аның рус теленә нотариаль таныкланган тәрҗемәсе.

4. Халыкның мәшгульлек үзәге белгече тарафыннан финанс ярдәмен билгеләү һәм халыкның мәшгульлек үзәге юлламасы буенча эшкә урнашу өчен башка җирлеккә вакытлыча эшкә урнашу өчен күченгәндә (яңа яшәү урынына күченеп урнашканда) эшсез гражданинга күчерү турында карарны кабул итү өчен эшсез гражданин 515 номерлы тәртипкә 1-4 нче кушымталарга туры китерелгән форма буенча гариза тапшыра, түбәндәге документларны теркәп:

вакытлыча эшкә урнашу өчен башка җирлеккә күченгәндә:

эшкә алучы белән төзелгән, билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе законнарына туры китереп эшкә алучы тарафыннан таныкланган хезмәт шартнамәсенең күчермәсен;

эш бирүче тарафыннан тиешенчә таныкланган хезмәт кенәгәсенең күчерәсе (оригинал тапшырылмый торган очракта) һәм (яки) әлеге эш бирүчедә хезмәт эшчәнлеге турында Россия Федерациясе Хезмәт кодексының $66^1$ статьясында билгеләнгән тәртиптә алынган белешмәләр (2020 елның 1 гыйнварына кадәрге чорга):

- 515 номерлы Тәртипнең 2.1.2.1 һәм 2.1.2.2 пунктларында каралган транспорт һәм тәүлек чыгымнарын өлешчә компенсацияләү очрагында кабул итү датасын һәм эш урынын күрсәтеп;

- эш урынын күрсәтеп, хезмәт килешүенең яки күчену турындагы килешүнең вакыты бетүгә бәйле рәвештә эштән җибәрү турындагы язу белән, – компенсациянең бер өлеше алдарак алынган очракта;

- 515 номерлы Тәртипнең 2.1.2 пунктында каралган финанс ярдәме алуга гариза элегрәк бирелмәгән булса, күченү турындагы килешүнең гамәлдә булу чоры беткәч эшкә алу датасын, эш урынын, эштән китү датасын һәм эштән китү нигезләрен күрсәтеп;

515 номерлы тәртипнең 2.1.2.1 һәм 2.1.2.2 пунктларында каралган чыгымнар турындагы белешмәләрне раслаучы документларның төп нөсхәләрен (515 номерлы Тәртипнең әлеге пунктларында каралган чыгымнарны компенсацияләү очрагында);

515 номерлы тәртипнең 2.1.2 пункты нигезендә компенсацияләнергә тиешле чыгымнар турында белешмәләрне раслаучы документларның төп нөсхәләрен (515 номерлы Тәртипнең 2.1.5 пункты нигезендә элегрәк өлешчә компенсацияләү

очрагында);

515 номерлы тәртипнең 2.1.2 пункты нигезендә компенсацияләнергә тиешле чыгымнар турында белешмәләрне раслаучы документларның төп нөсхәләрен (515 номерлы Тәртипнең 2.1.5 һәм 2.1.6 пунктлары нигезендә элегрәк компенсация гамәлгә ашырылмаган очракта);

банкта яки башка кредит оешмасында ачтырылган шәхси счет (исәп-хисап счеты) күчермәсен;

эшкә урнашу өчен башка җирлеккә яңа яшәү урынына күченеп урнашканда:

эшкә алучы белән төзелгән, Россия Федерациясе законнарына туры китереп эшкә алучы тарафыннан таныкланган хезмәт шартнамәсенең күчермәсен;

эш бирүче тарафыннан тиешенчә расланган хезмәт кенәгәсенең (төп нөсхәсе куелмаган очракта) күчермәсе һәм (яки) хезмәткәрнең әлеге эш бирүчедә хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүмат, эшкә алу датасын һәм эш урынын күрсәтеп (2020 елның 1 гыйнварына кадәрге чор өчен):

эшсез гражданинның һәм аның гаилә әгъзаларының күченеп урнашу буенча транспорт чыгымнары, яңа яшәү урынына барган вакытта тәүлеклек чыгымнары һәм элеккеге яшәү урыныннан яңа яшәү урынына йорт мөлкәтен алып бару бәясен түләү чыгымнары (шартнамәләр, башкарылган эшләр актлары, исәп-хисап-фактуралары, квитанцияләр, касса чеклары һ.б.) турында белешмәләрне раслаучы документларның төп нөсхәләре;

эшсез гражданинның шәхесен таныклаучы документ күчермәсен;

эшсез гражданинның гаилә әгъзаларының шәхесен таныклаучы документларның күчермәләрен;

гаилә әгъзаларының персональ белешмәләрен тапшырганда эшсез гражданинның гаилә әгъзалары исеменнән яки аларның законлы вәкилләре исеменнән эш итүгә вәкаләтле булуын раслаучы документны;

банкта яки башка кредит оешмасында ачтырылган шәхси счет (исәп-хисап счеты) күчермәсен.

Гариза эшсез гражданинның шәхси яки «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә гади электрон имзасы белән таныклана.

Гаризаны почта аша җибәргәндә, аңа теркәлә торган документларның күчермәләре, паспорт күчермәсен яисә аны алмаштыра торган документ күчермәсен дә кертеп, Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнгән тәртиптә таныкланган булырга тиеш.

Мөрәҗәгать итүченең вәкиле өстәмә рәвештә мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрендә эш итү вәкаләтләрен раслый торган документларның күчермәләрен тапшыра.

Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гариза кәгазен эшсез гражданин халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар эшсез гражданин тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

шәхсән (ышаныч кәгазе нигезендә эшсез гражданин исеменнән эш итүче зат тарафыннан);

почта аша.

Гариза белән аңа теркәлә торган документлар шулай ук эшсез гражданин тарафыннан гади электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмати-телекоммуникация челтәре аша, шул исәптән «Интернет» челтәре аша да, тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.

Документларның күчермәләре, әгәр алар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә күрсәтелә һәм халыкның мәшгульлек үзәге белгече тарафыннан таныклана.»;

2.6 пунктта:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча түбәндәгеләр алына:

-эшсез гражданинның 14 яшенә җитмәгән гаилә әгъзаларының тууын дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр (ГХАТ органнарында);

гаилә коруны дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр (ГХАТ органнарында);

гаилә составы турында белешмәләр (гражданнарның тору урыны һәм яшәү урыны буенча теркәү исәбенә алучы ашыруга вәкаләтле оешмаларда);

гражданинның әлеге эш бирүчедәге хезмәт эшчәнлеге турында Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 66[1] статьясында билгеләнгән тәртиптә алынган белешмәләр (2020 елның 1 гыйнварыннан башланган чорга) (ТР Пенсия фондында);

хосусый программадан өземтә, түбәндәгеләрне үз эченә ала:

эшкә урнаштыру һәм хезмәт шартлары буенча киңәшләр (мөмкин булган эш төрләре һәм башкарылуы кыен булган хезмәт гамәлләре (функцияләр);

организмының бозылган үзлекләрен һәм яшәешендәге чикләмәләрен исәпкә алып, инвалидка киңәш ителә торган хезмәт һәм профессиональ эшчәнлек төрләрен сайлау өчен белешмәләр.

Әлеге белешмәләр, аларны медик-социаль экспертиза федераль учреждениесе җибәрмәгән очракта, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Медик-социаль экспертиза федераль дәүләт учреждениеләреннән бирелә торган инвалидны тернәкләндерү яки абилитацияләүнең хосусый программасын, инвалид баланы теркнәкләндерү яки абилитацияләүнең хосусый программасын эшләү һәм гамәлгә ашыру тәртибен һәм аларның формаларын раслау турында» 2017 елның 13 июнендәге 486н номерлы боерыгының (алга таба – 486н номерлы боерык) 1 нче кушымтасындагы 14 пунктының «д» пунктчасы нигезендә мөстәкыйль соратып алына.

Эшсез гражданин әлеге пункттагы белешмәләрдән торган документларны, шул исәптән, мөмкинлек булганда, электрон рәвештә дә, тапшырырга хокуклы.

Югарыда күрсәтелгән белешмәләрдән торучы документларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

Эшсез гражданин тапшырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Административ регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән.

Мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торганын да, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалары карамагында булган документлар һәм мәгълүмат тапшыруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) төгәл булмавы турында күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүмат тапшыруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә элегрәк электрон үрнәкләре таныкланган документларны һәм мәгълүматларны кәгазьдә тапшыруны, мондый документларга тамгалар кертү яки аларны бетерү дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып торган очраклардан тыш һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш.»;

3 нче бүлектә:

3.4.2.1 пунктның тугызынчы абзацында «2.6 пунктның бишенче абзацында» сүзләрен «2.6 пунктның тугызынчы абзацында» сүзләренә алмаштырырга;

3.4.2.2 пунктның сигезенче абзацында «2.6 пунктның бишенче абзацында» сүзләрен «2.6 пунктның тугызынчы абзацында» сүзләренә алмаштырырга;

3.4.9 пунктның бишенче абзацында «пункт» сүзен «пунктча» сүзенә алмаштырырга;

3.4.10 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Эшсез гражданинга финанс ярдәме күрсәтү турында карар кабул ителгән очракта, финанс ярдәме эшсез гражданин гариза һәм 2.5 пунктның 4 пунктчасында күрсәтелгән документлар тапшырылганда һәм әлеге Административ регламентның 2.6 пунктының бишенче абзацында күрсәтелгән белешмәләр булган очракта билгеләнә.»;

дүртенче абзацта «пункт» сүзен «пункчат» сүзенә алмаштырырга;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Административ регламентның 2.5 пунктының 4 пунктчасында күрсәтелгән, тапшырылган документлар нигезендә һәм 2.6 пунктның бишенче абзацында күрсәтелгән белешмәләр булган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече Дәүләт хезмәтләреннән файдаланучылар регистрында эшсез гражданин турында белешмәләр эзләтү параметрларын билгели һәм эшсез гражданинга фи-

нанс ярдәме билгеләү яки финанс ярдәме билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итә.»;

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Халыкның мәшгульлек үзәге белгече Дәүләт хезмәтләреннән файдаланучылар регистрына гражданин тарафыннан тапшырылган, әлеге Административ регламентның 2.5 пунктының 4 пунктчасында күрсәтелгән документларда булган һәм 2.6 пунктның бишенче абзацындагы белешмәләрне кертә.»;

3.5.3.1 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.5.3.1. Тапшырылган документлар составында һәм халыкның мәшгульлек үзәгендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле, әлеге Административ регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән, эшсез гражданин мөстәкыйль тапшырырга хокуклы булган документлар (белешмәләр) булмаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә сорала торган белешмәләр белән эш итүче дәүләт органнарына тиешле рәсми мөрәҗәгатьне (рәсми мөрәҗәгатьләрне) җибәрә:

-эшсез гражданинның 14 яшенә җитмәгән гаилә әгъзаларының тууын дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр (ГХАТ органнарында);

гаилә коруны дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр (ГХАТ органнарында);

гаилә составы турында белешмәләр (гражданнарның тору урыны һәм яшәү урыны буенча теркәү исәбенә алучы ашыруга вәкаләтле оешмаларда);

гражданинның әлеге эш бирүчедәге хезмәт эшчәнлеге турында Россия Федерациясе Хезмәт кодексының $66^1$ статьясында билгеләнгән тәртиптә алынган белешмәләр (2020 елның 1 гыйнварыннан башланган чорга) (ТР Пенсия фондында);

хосусый программадан өземтә, түбәндәгеләрне үз эченә ала:

эшкә урнаштыру һәм хезмәт шартлары буенча киңәшләр (мөмкин булган эш төрләре һәм башкарылуы кыен булган хезмәт гамәлләре (функцияләр);

организмының бозылган үзлекләрен һәм яшәешендәге чикләмәләрен исәпкә алып, инвалидка киңәш ителә торган хезмәт һәм профессиональ эшчәнлек төрләрен сайлау өчен белешмәләр.

Үтәү вакыты: процедура гариза яки халыкның мәшгульлек үзәге белгече тәкъдиме алынган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр.»;

3.5.10 пунктта:

икенче абзацта «пункт» сүзен «пунктча» сүзенә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «пункт» сүзен «пункчат» сүзенә алмаштырырга;

3.5.11 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Эшсез гражданинга һәм аның гаилә әгъзаларына финанс ярдәме күрсәтү турында карар кабул ителгән очракта, финанс ярдәме эшсез гражданин гариза һәм 2.5 пунктның 4 пунктчасында күрсәтелгән документлар тапшырылганда һәм әлеге Административ регламентның 2.6 пунктының бишенче абзацында күрсәтелгән белешмәләр булган очракта билгеләнә.»;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Эшсез гражданин 515 номерлы Тәртипнең 4 нче кушымтасына ярашлы форма буенча гариза һәм әлеге Административ регламентның 2.5 пунктының 4 пунктчасында күрсәтелгән документлар белән яңа яшәү урыны буенча (Татарстан Республикасы чикләрендә халыкның мәшгульлек үзәге юлламасы буенча эшкә урнаштыру өчен эшсез гражданинны һәм аның гаилә әгъзаларын башка җирлеккә күчергәндә) халыкның мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать иткән очракта һәм гражданин тарафыннан күченү турында килешү күрсәтелгән очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече әлеге Административ регламентның 2.5 пунктының 4 пунктчасында каралган документларның һәм 2.6 пунктның бишенче абзацында каралган белешмәләрнең булуын һәм әлеге Административ регламентның 2.8 пункты нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булу-булмавын тикшерә.»;

дүртенче абзацта «2.5 пунктның 4 пунктында күрсәтелгән документлар» сүзләрен «2.5 пунктның 4 пунктчасында һәм 2.6 пунктның бишенче абзацында күрсәтелгән документлар (белешмәләр)» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «пункт» сүзен «пунктча» сүзенә алмаштырырга;

җиденче абзацта «пункт» сүзен «пунктча» сүзенә алмаштырырга;

сигезенче абзацта «2.5 пунктның 4 пунктында күрсәтелгән документлар» сүзләрен «2.5 пунктның 4 пунктчасында һәм 2.6 пунктның бишенче абзацында күрсәтелгән документлар (белешмәләр)» сүзләренә алмаштырырга;

5 бүлектә:

5.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.4. Халыкның мәшгульлек үзәгенә, Министрлыкка яки күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы затка алынган шикаять ул алынган көненнән соңгы эш көнендә теркәлергә тиеш.

Шикаятьне карап тикшерү чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәтен күрсәтә торган органның (учреждениенең), шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтә торган органдагы вазыйфаи затның (белгечнең) яки дәүләт хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.».